РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423586, г. Нижнекамск, пр. Строителей, 12
тел./факс (8555) 41-70-00

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

423586, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
тел./факс (8555) 41-70-00

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

№ 23 2022 елның 14 апреле

Түбән Кама муниципаль районы Советының 2011 елның 22 декабрендәге 40 номерлы «Түбән Кама муниципаль районы муниципаль мөлкәтенә ия булу, файдалану һәм эш итү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Граждан кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Конкуренцияне яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр турында» 2002 елның 14 ноябрендәге 161-ФЗ номерлы Федераль закон, «Автоном учреждениеләр турында» 2006 елның 3 ноябрендәге 174-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Уставы нигезендә эш итеп, оператив идарә хокукында яки хуҗалык алып бару хокукында беркетелгән муниципаль мөлкәтне арендага бирү тәртибен билгеләү максатыннан, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль районы Советының 2011 елның 22 декабрендәге 40 номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районы муниципаль мөлкәтенә ия булу, файдалану һәм эш итү тәртибе турындагы Нигезләмәнең 13.3.2 пунктының 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) Балаларга белем бирү, тәрбия бирү, үстерү, социаль яклау һәм социаль хезмәт күрсәтүне тәэмин итү өчен аренда шартнамәсе төзү нәтиҗәләрен бәяләү турында комиссия бәяләмәсе».

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны социаль-икътисади үсеш, бюджет-финанс мәсьәләләре һәм муниципаль милек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль районы Башлыгы вазыйфаларын башкаручы,
Башлык урынбасары А.В.Умников